| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**05.08.2017** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2125** |

Зеленодольск муниципаль районы
чикләрендә янгын куркынычсызлыгының
беренчел чараларын тәэмин итү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, “Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп, муниципаль берәмлек территориясендә халыкны һәм гражданнарның мөлкәтен янгыннан саклау максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турындагы нигезләмәне, кушымтада каралганча, расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk. tatarstan.ru)урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль
районы Башкарма комитетының
2017 елның 05 августындагы
2125 номерлы карарына
кушымта

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында нигезләмә

1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘ

1.1. Әлеге Нигезләмә "Янгын куркынычсызлыгы турында" 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы (2004 елның 22 августындагы № 122-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә), "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә эшләнгән һәм муниципаль берәмлек чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы буенча оештыру-хокукый, финанс, матди-техник тәэмин итүне билгели.

1.2. Муниципаль берәмлек чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кагыла.

1.3. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр һәм терминнар:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары - янгын сүндерүне оештыру чаралары комплексының бер өлеше булып торган, янгыннарны булдырмау , кешеләрне һәм мөлкәтне янгыннан коткару буенча билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән нормаларны һәм кагыйдәләрне гамәлгә ашыру.

- янгынга каршы режим - кешеләрнең үз-үзләрен тоту кагыйдәләре, куркынычсызлык таләпләрен бозуны кисәтүне һәм янгыннарны сүндерүне тәэмин итүче биналарны (территорияләрне) җитештерүне һәм (яки) тотуны оештыру тәртибе;

- янгыннарны профилактикалау - янгыннарның килеп чыгу мөмкинлеген булдырмауга һәм аларның нәтиҗәләрен чикләүгә юнәлдерелгән превентив чаралар җыелмасы;

- Янгынга каршы пропаганда - халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары аша, махсус белешмәләр, реклама продукциясен бастырып чыгару һәм тарату, халыкка киңәшләр бирү, тематик күргәзмәләр, смотрлар, конкурслар, конференцияләр оештыру һәм халыкка мәгълүмат җиткерүнең Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка формаларын кулланып гамәлгә ашырыла торган, халыкка янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү проблемалары һәм юллары турында максатчан мәгълүмат бирү.

- янгын сүндерүнең беренчел чаралары -янгын чыгуның башлангыч чорында янгын белән көрәшү өчен кешеләр кулдан-кулга йөртә торган яки махсус машинадагы янгын сүндерү чаралары;

- муниципаль янгын сагы - янгыннарны булдырмау (янгыннарны кисәтү), кешеләрне һәм мөлкәтне янгыннан коткаруны тәэмин итү максатында муниципаль берәмлек территориясендә төзелә торган янгын саклау төре.

- <u>янгыннан ирекле саклау (ДПО)</u> - янгын сүндерү машиналары булмаган ирекле янгын сүндерү дружиналарының бер яки берничә бүлекчәләре, яки янгын сүндерү җиһазлары, янгын сүндерү мотопомпалары яки янгын сүндерү машиналары булган ирекле янгын сүндерү командалары;
- <u>ирекле янгын сүндерүче</u> - янгыннарны кисәтү, кешеләрне һәм мөлкәтне янгыннардан коткару буенча янгыннан ирекле саклау бүлекчәләре эшчәнлегендә турыдан-туры ирекле нигездә (хезмәт килешүе төземичә) катнашучы граждан. . Янгыннан ирекле саклауда катнашу муниципаль берәмлекнең авыл җирлеге администрациясе тарафыннан билгеләнгән социаль әһәмиятле эшләрнең бер төре булып тора.

## 2. ЯНГЫН КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫНЫҢ БЕРЕНЧЕЛ ЧАРАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

2.1. Муниципаль берәмлек территориясендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларына түбәндәгеләр керә:
- янгыннарны кисәтү (янгыннарны профилактикалау), янгыннан ирекле саклау бүлекчәләре составында кешеләрне һәм мөлкәтне янгыннан коткару буенча эшләргә муниципаль берәмлек халкын җәлеп итү өчен кирәкле шартларны тәэмин итү;
- янгынга каршы пропаганда үткәрү һәм халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү;
- муниципаль учреждениеләрне янгын сүндерүнең беренчел чаралары белән җиһазландыру;
- муниципаль берәмлек территориясендә төзелеш алып бару һәм аны планировкалау өчен шәһәр төзелеше һәм проект-смета документациясен эшләгәндә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү;
-муниципаль берәмлек өчен урман һәм торф янгыннары вакытында муниципаль берәмлек биналарына, төзелешенә һәм корылмаларына ут күчү мөмкинлеген булдырмаучы чаралар эшләү һәм башкару;
- тотрыклы коры, эссе һәм җилле һава шартларында муниципаль берәмлек территориясен патрульләүне оештыруны;
- дәүләт янгын сагына янгын чыгу турында хәбәр итү өчен муниципаль берәмлекне төзек телефон яки радиоэлемтә белән тәэмин итү;
- муниципаль берәмлек территориясен янучан калдыклардан, чүп-чардан, коры үсемлекләрдән үз вакытында чистарту;
- юлларның елның теләсә кайсы вакытында, гомуми файдаланудагы региональ һәм федераль әһәмиятле автомобиль юлларыннан тыш, муниципаль берәмлек чикләрендәге юлларны биналарга, төзелешләргә һәм корылмаларга керү өчен төзек хәлдә тоту;
- янгынга каршы су белән тәэмин итү системаларын төзек хәлдә тоту;
- мөлкәтне һәм объектларны, шулай ук муниципаль милек объектларында янгын сүндерүнең беренчел чараларын төзек хәлдә тоту.
- индивидуаль торак йортлар өчен янгын сүндерүнең беренчел чаралары исемлеген раслау;

- ирекле янгын сүндерүчеләр эшчәнлегенә ярдәм итү, халыкны янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә җәлеп итү;
- янгынга каршы махсус режим урнаштыру;
- муниципаль берәмлекнең торак пунктларында янгыннарны профилактикалау.

## 3. МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК ЧИКЛӘРЕНДӘ ЯНГЫН КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫНЫҢ БЕРЕНЧЕЛ ЧАРАЛАРЫН ТӘЭМИН ИТҮ

3.1. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүнең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
- янгыннарны булдырмау (янгыннарны профилактикалау) чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;
- янгын вакытында кешеләрне һәм мөлкәтне коткару.
3.2. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын оештыру-хокукый тәэмин итү түбәндәгеләрне күздә тота:
- янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә оештыру-хокукый, финанс, матди-техник тәэмин итү мәсьәләләрен муниципаль хокукый җайга салу;
- муниципаль берәмлекнең һәм муниципаль милек объектларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;
- янгыннан ирекле саклау бүлекчәләрен булдыру, үзгәртеп оештыру һәм бетерү;
- муниципаль берәмлек чикләрендә янгын сүндерү өчен тәртип урнаштыру, көч һәм чаралар җәлеп итү;
- шәһәр төзелеше эшчәнлеген контрольдә тоту, муниципаль берәмлек территориясендә төзелеш һәм планлаштыру вакытында янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү;
- Дәүләт янгынга каршы хезмәте белән берлектә үзәкләштерелгән су белән тәэмин ителгән торак пунктлар гидрантлар белән җиһазландыру;
- янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә пропаганда оештыру, янгын сүндерү-техник белемнәрен таратуга ярдәм итү;
-муниципаль милектә булган торак йортларның янгын куркынычсызлыгы таләпләренә туры килүен тикшерүне оештыру;
- кешеләрнең күпләп була торган чараларны оештыруны һәм үткәрүне контрольдә тоту.
3.3. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын финанс белән тәэмин итү муниципаль берәмлек бюджетында әлеге максатларга каралган акчалар чикләрендә башкарыла һәм түбәндәгеләрне күздә тота:
- янгын куркынычсызлыгы чыгымнары өлешендә җирле бюджетны эшләү, раслау һәм үтәү;
- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүне, шул исәптән халыкның янгынга каршы көрәштә катнашуын социаль һәм матди стимуллаштыруны гамәлгә ашыру;
- муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән түбәндәгеләргә бәйле чыгымнар башкарыла:
а) җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру һәм муниципаль мөлкәтне төзүгә һәм (яисә) арттыруга китерү;

б) янгыннан ирекле саклауны булдыру, үзгәртеп оештыру, бетерү һәм аны карап тоту;
в) халык арасында янгынга каршы пропаганда һәм беренчел янгын куркынычсызлыгы чаралары үткәрү;
г) муниципаль берәмлек администрациясе тарафыннан янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм янгын-техник белемнәрне таратуга ярдәм итү буенча кабул ителгән карарлар турында халыкка хәбәр итү;
3.4. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын матди-техник яктан тәэмин итү түбәндәгеләрне күздә тота:
- муниципаль милектә булган торак һәм иҗтимагый биналарны янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын төзек хәлдә тоту буенча эшләр оештыру;
- муниципаль берәмлек чикләрендә гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, биналарга, корылмаларга бару юлларын карап тоту һәм янгын урынына янгын техникасының тоткарлыксыз үтүен тәэмин итү;
- янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының тиешле торышын тәэмин итү;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын гамәлгә ашыру;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыруга бәйле муниципаль заказларны формалаштыру һәм урнаштыру.

4. ЯНГЫН КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫНЫҢ БЕРЕНЧЕЛ ЧАРАЛАРЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ ВӘКАЛӘТЛӘРЕ

Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек Башкарма комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:
- муниципаль берәмлек территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча кабул ителгән карарлар турында халыкка хәбәр итү;
- янгынга каршы пропаганда үткәрү һәм халыкны, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларын беренчел янгын куркынычсызлыгы чаралары буенча мөстәкыйль рәвештә яки шартнамә нигезендә башка милек формасындагы оешмаларны җәлеп итү юлы  белән укыту оештыру;
- муниципаль һәм янгыннан ирекле саклау эшчәнлеген оештыру;
- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру (янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының тиешле торышын тәэмин итү, муниципаль торак фондының һәм муниципаль торак булмаган биналарның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, торак пунктны телефон элемтәсе белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру);
- муниципаль берәмлек территориясендә төзелеш алып бару һәм аны планировкалау өчен шәһәр төзелеше һәм проект-смета документациясен эшләгәндә янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру;
- ирекле янгын сүндерүчеләр көче белән тотрыклы коры, эссе һәм җилле һава шартларында муниципаль берәмлек территориясен патрульләүне оештыру;

- муниципаль берәмлек территориясен янучан калдыклардан, чүп-чардан, коры үсемлекләрдән чистарту;
- юлларның елның теләсә кайсы вакытында, гомуми файдаланудагы региональ һәм федераль әһәмиятле автомобиль юлларыннан тыш, муниципаль берәмлек чикләрендәге юлларны биналарга, төзелешләргә һәм корылмаларга керү өчен төзек хәлдә тоту;
- янгынга каршы су белән тәэмин итү системаларын төзек хәлдә тоту;
- мөлкәтне һәм объектларны, шулай ук муниципаль милек объектларында янгын сүндерүнең беренчел чараларын төзек хәлдә тоту;
- ирекле янгын сүндерүчеләр эшчәнлегенә ярдәм итү, халыкны янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүгә җәлеп итү;
- янгын сагының башка төрләре (муниципаль, ведомство, хосусый һәм янгыннан ирекле саклау) арасында үзара хезмәттәшлекне һәм мөнәсәбәтләрне җайга салу;
- җирле үзидарә органнарының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү компетенциясе өлешендә Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәүне оештыру.